| СОВЕТ<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

| **РЕШЕНИЕ**<br>03.08.2015 | Зеленодольск ш. | **КАРАР**<br>№337 |
|---|---|---|

«Зеленодольск муниципаль районының аерым муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында» Зеленодольск шәһәре Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 2015 елның 31 июлендәге 552 номерлы карары белән күрсәтелгән Зеленодольск муниципаль районы Советының инициативасын карап, муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукларын тәэмин итү һәм муниципаль берәмлекләр чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча аларның фикерләрен ачыклау максатларында, Зеленодольск шәһәре Советы **карар бирә:**

1. «Зеленодольск муниципаль районы Советының Зеленодольск муниципаль районының аерым муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турындагы инициативасын хуплау турында» Зеленодольск шәһәре Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне 2015 елның 15 августына билгеләргә (кушымта итеп бирелә).

2. Билгеләргә:

2.1. гавами тыңлаулар үткәрелү урыны - А.М.Горький исемендәге ЦКиНТ бинасы: ТР, Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 46 йорт;

2.2. үткәрү вакыты - 16.00;

2.3. уздыру вакыты - 1 көн;

2.4. фикер алыша торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр белдерелергә мөмкин булган адрес чыгышлар хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар бирелергә мөмкин. ТР, Зеленодольск ш., Ленин урамы, 41а, каб. 306 (эш көннәрендә - 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр);

2.5. чыгышлар хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар бирү вакыты - 2015 елның 8 августына кадәр.

3. Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Зеленодольск шәһәре Советының билгеләнгән тәртиптә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда карары проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләүне һәм уздыруны йөкләргә.

4. Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитетына, «Зеленодольск муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә гавами тыңлауларда катнашу өчен вәкилләр җибәрергә тәкъдим итәргә.

5. 2015 елның 4 августына кадәр әлеге карарны һәм әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән карар проекты Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зеленодольск муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск шәһәре Советының Законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**Зеленодольск шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**

**Зеленодольск шәһәре Советының 2015 елның 03 августындагы 337 номерлы карарына кушымта**

**проект**

**Зеленодольск шәһәре Советы карары**

2015 елның "_____" __________ №_____

Зеленодольск муниципаль районының аерым муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында Зеленодольск муниципаль районы Советы инициативасын хуплау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 2015 елның 31 июлендәге 552 номерлы карары белән күрсәтелгән Зеленодольск муниципаль районы Советы инициативасын карап, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зеленодольск шәһәре Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының инициативасын хупларга һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрен карта-схема нигезендә үзгәртүгә ризалык бирергә. (әлеге карарга 1 нче кушымта).
2. «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чикләре тасвирламасын Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләр чикләре картасы нигезендә (әлеге карарга 2 нче кушымта) килештерергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**